Республика Татарстан
**СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

**РЕШЕНИЕ**
**25.11.2021**

**КАРАР**
**№ 15**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» Сарман районының Мортыштамак авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

1. 5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчалар түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына тапшыра, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;»

2. 5 статьяның 10 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне куллануның, бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә»;

3. 5 статьяның 11 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының бюджетка керүнең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;”;

Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы — И.Н.Һадиуллин